Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы

# Мәктәп пульсы



№6
Апрель 2019 г.

## Апрель - месячник экологии

***Потребность общения с природой остается одной из острейших у человека современной эпохи. Духовные потребности человека тесно связаны с развитием чувства добра сострадания, любви и заботы о природе, с осознанием вечной и неиссякаемой красоты.***

### *1 апреля – Международный день птиц*

Впервые «День птиц» как массовый детский праздник стал проводиться в США. В 1894 году его организовали педагог из местечка Оил-Сити Чарльз Бабкок. Вскоре его поддержала популярная газета «Петербургская телеграфная хроника». Издание организовало даже специальный клуб по охране птиц. Вскоре «День птиц» стал проводиться как народный праздник во всех штатах Старого и Нового Света. А дальше проник и в Россию.



Вновь о «Дне птиц» вспомнили в нашей стране в середине 20 годов. В мае 1924 года юннатами Центральной биостанции юных натуралистов под Москвой было развешено несколько десятков дуплянок, а через год ребята провели первый в стране официальный «День птиц». Они развешивали скворечники на Воробьевых горах.

Есть сведения, что в этом празднике принял участие и сам Маяковский, имевший дачу недалеко о биостанции.



В 1927 году «День птиц» подхватила вся Москва: было развешено более 1000 птичьих домиков. С 1928 года «День птиц» зашагал о всей стране. В акции принимало участие более 65 тысяч энтузиастов, ежегодно развешивалось до 15 тысяч скворечников…

Весна - прекрасная пора для всего живого: пробуждается природа, и мы с нетерпением ждем наших друзей-пернатых странников. А они появятся вот-вот. Скворцы, грачи, жаворонки, трясогузки, ласточки, стрижи. Именно в это время проводится «День Птиц».

**Ильшат ШАКИРОВ,**

9Б класс

## Интересно знать!

- В среднем в день человек делает более 18 000 шагов.
- На протяжении жизни человек съедает около 27 тонн пищи, что равняется весу семи слонов.
- На шахматной доске разнообразных комбинаций больше, чем в нашей Вселенной атомов.
- Чтобы заснуть, нормальному человеку требуется в среднем 7 минут.
- В среднем мухи живут не более 2-х 3-х недель.
- Емкость мозга человека превышает 4 терабайта.
- Гигантский кальмар имеет самый большой глаз в мире.

## В этом выпуске:


| | |
|---|---|
| Матбугатта экология проблемалары | 2 |
| Татар рухы әле сүнмәгән | 3 |
| Тел дигән дәрья бар... | 3 |
| Ана теле бер | 4 |

# Матбугатта экология проблемалары

***Грек теленнән «эко» - йорт, ә «логос» тәгълимат, уку дип тәрҗемә ителә. Туган йортыбыз - Җир-Ананы саклау буенча без нинди эшләрдә катнаша алабыз? Файдалы гамәл кылу максатыннан, берничә ай дәвамында матбугат чаралары аша иң кызыклы экопроектларны барладык.***

- Мәктәбебездә даими уздырыла торган ***сыерчык оялары конкурсын*** күпләр яратып өлгерде. Республика буенча 1 апрельдән 31 майга кадәр дәвам итәүл. Мәсәлән, Балык Бистәсе Югары Тегермәнлек авылында урнашкан «Акчарлак» приютында тәрбияләнүче балалар укытучылары Марсель Хәсәнов белән остаханәләрендә сыерчык ояларын кыштан ук әзерли башлаулары турында мин журнал битеннән укып белдем. Иң әйбәт оялар башта мәктәпләрдә, районнарда сайланып алына, ә иң яхшылары министрлык тарафыннан бүләкләнәчәк икән.

- 2019 елның 1 гыйнварыннан «***Будет чисто» яшьләр экологик хәрәкәтенең республика штабында*** Татарстан буенча яшь натуралистлар хәрәкәте яңадан эшли башлады. Шул уңайдан 1 марттан 31 майга кадәр укулар уздырылачак. Яшь натуралистлар сафына 7 яшьтән алып 15 яшькә кадәр мәктәп укучылары керә ала. Казандагы университет мөгаллимнәре тарафыннан төзелгән видеодәресләр, алтмышар минуттан торган 6 программа нигезендә белем алганнан соң, онлайн-тест узарга кирәк.



Шулай итеп яшь натуралистлар хәрәкәтенең бер кыйпылчыгына әйләнәсең. Алай гына да түгел, һәр отрядның белемен тикшерү өчен отрядны җитәкләүче укытучы тарафыннан «Түгәрәк көндәлеге» алып барылачак, иң-иңнәрне аерым билгеләп үтәчәкләр. Җәй көне үзең кебек табигать сагында торучы яшьтәшләрең белән бергәләп палаткалы лагерьда бушлай ял итәргә һәм июль аенда зурлап уздырылачак яшь натуралистлар слетында катнашырга мөмкин.


Яшь натуралистлар хәрәкәтенә кагылышлы барлык сорауларны yunnat-y100@gmail.com электрон почтасына юлларга мөмкин.



- Активистларның эшләре чын күңелдән башкарылса да, һәр хезмәт тарихка кереп калырга тиешле. Шуңа күрә экологик хәрәкәттә катнашып,төрле чаралар оештыручылар өчен ***«Яшел зачет кенәгәсе»*** бирәләр, һәм һәр башкарылган эш штаб җитәкчесе имзасы һәм мөһере белән биредә теркәлеп барыла.

Ел азагында хәрәкәт эшчәнлегенә нәтиҗә ясаганда, әлеге документта күрсәтелгән эш нәтиҗәләре исәпкә алына. Ә исәпкә алуны бик телиләр биредә, чөнки иң актив 7 кешегә бүләк итеп велосипедлар тапшырыла икән. Бу турыда да мин матбугат битләреннән укып белдем.

- ***“Гаилә һәм мәктәп”*** журналында даими рәвештә чыгып килүче ***“Табигать сагында”*** рубрикасы бик кызыклы һәм файдалы экологик проектлар тәкъдим итә. Уку елы башыннан старт алган ***«Мәктәп экопатруле» V Республика бәйгесе*** 2019 елның 31 августына кадәр дәвам итәчәк. Катнашу өчен телефонга «Школьный экопатруль» мобиль кушымтасын урнаштырырга гына кирәк. Аннан законсыз чүплекләрне, пычрак суларның әйләнә-тирәгә зыян салу очракларын фото-видеога төшереп, ТР Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына юллыйсың.




Әлеге сигналлар буенча инспекторлар, күрсәтелгән урыннарга чыгып,тиешле чаралар күрәчәк. Җиңүчеләрне сентябрь-октябрь айларында кыйммәтле бүләкләр белән тәбрикләячәкләр. Узган уку елында «Мәктәп экопатруле» аша укучылардан 7200 фотохәбәр килеп ирешкән.

- Казандагы Түбән Кабан күлен чүптән чистартучы аккош турындагы социаль челтәрләрдәге популяр видеоны күпләрегез хәтерлидер. Әлеге аккош - санитар-экологик икеайлык символы. Яшь экологларны рухландыручы ***«ЭкоЯз»*** дип аталган бу кызыклы проект 1 апрельдән 31 майга кадәр дәвам итә. «ЭкоЯз» акциясе кысаларында урамнар чүптән арындырыла, агачлар утыртыла. Әлеге акциядә безнең мәктәп укучылары да бик теләп катнаша.

**Эльвина Хәйретдинова,**
7Б сыйныфы

*...Офыктагы маяк булып алга чакыр*
*Татар теле, Тукай теле, Туган телем!..*
*Акъегет*

# Тел дигән дәрья бар...

***Һәр халыкның туган теле – аның мәдәнияте, тарихи көзгесе. Шуңа да телебез сафлыгы, матурлыгы, аһәңлелеге өчен барыбызга да армый-талмый көрәшергә, эшләргә кирәк.***

Халкыбызның культура дәрәҗәсе елдан-ел үсә, аның рухи яктан формалашуында сүзнең роле арта бара, эстетик зәвык камилләшә, яңадан-яңа китаплар чыгып тора, радиодан, телевидениедән тел турында кызыклы тапшырулар алып барыла. Болар барысы да бездә телнең тарихы, үсеше, яшәеше, төзелеше турында күп санлы сораулар тууга сәбәп була.

Безне чолгап алган чынбарлык белән сүз арасында нинди дә булса бәйләнеш бармы? Телебез язмышы ни хәлдә? Сүзнең серле көче нидә?

«Татар халык мәкальләренең икенче томын алып, «Тел һәм сүз» дигән бүлеген ачам. Анда халкыбызның тел турында иң үткен, иң оста, иң тапкыр, иң мәгънәле мәкальләре тупланган. Аларның һәркайсы — үзе бер дөнья. Телнең асылы, тел һәм уй-фикер, (татлы, ачы, яхшы, яман, озын, кыска, үткен, матур...), сүз һәм аның көче, сүзне әйтә-сөйли белү, сөйләү әдәбе, осталык һәм сөйләм культурасы, телдән-сүздән туган төрле хәлләр турында ике меңнән артык мәкаль табарга мөмкин. Халык тикмәгә генә «Сүз — фикернең коралы» димәгән. Сүз кешенең уй-фикерен, хисләрен белдерә. Җәмгыятьнең яшәү һәм үсү шарты булган телнең үзәген сүзләр тәшкил итә.

Ә без сүзнең тәмен белеп сөйләшә, аралышабызмы бүген? Бу сорауга җавап бирүе бик җиңел кебек тоела. Әлеге сорау ничәмә-ничә еллар буена галимнәрне борчып килгән һәм әле хәзер дә моңа канәгатьләнерлек җавап бирелгәне юк. Ә ни өчен шулай?

**Рәсимә ИБРАЕВА,**
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

# Татар рухы әле сүнмәгән

Татар тарихы белгече, галим, педагог Искәндәр Аяз улы Гыйләҗев (“Безнең мирас”, №7) телебезне саклап калу өчен шушы юнәлешләрдә хәрәкәт итәргә тәкъдим итә:

- шәһәрдә чын татар мохитен булдыру;

- сыйфатлы, зәвыклы, шәһәр халкына да, авыл халкына да кызыклы, яхшы татар телевидениесен булдыру – телне саклауда зарури бер шарт. Хәзерге көндә «Татарстан Яңа Гасыр» бу юнәлештә эшли, «ТНВ-Планета», «Яшь ТНВ» дигән канал да барлыкка килде. Ләкин кайвакыт бу каналларны карагач, татар тормышы бары тик җырбиюдән генә тора дигән фикер туа.

- тагын бер актив үсә торган юнәлеш – интернет һәм компьютер технологияләре. Татар телен саклауда интернет гаҗәеп роль уйнарга мөмкин, чөнки яшьләрнең күбесе көне-төне интернетта аралаша. Бу күренешне без үз файдабызга куллана алабыз.

- тулы канлы, нәтиҗәле эшли торган, балаларны һәм ата-аналарны җәлеп итәрлек татар мәгариф системасын булдыру бик мөһим.

- татар телен оныткан, ләкин татар үзаңын югалтмаган, үзләрен татар дип саный торган яшьләр белән эш алып бару бик тә актуаль бурыч булып күренә, чөнки аларның йөрәкләрендә, күңелләрендә татар рухы әле сүнмәгән.

Мин бу юнәлешләр белән килешәм. Иң мөһиме, туган телгә ихтирам хисен һәркем



үзеннән, үз гаиләсеннән башларга тиеш дип уйлыйм мин. Әгәр без үз милләттәшләребез белән туган телебездә аралашмасак, башка милләт кешеләре безнең телебезне хөрмәт итәр микән?! Шушы көнгә кадәр нинди авырлыклар аша үтеп сакланып калган телебезне югалтырга безнең хакыбыз юк!

Телебезне югалта калсак, ата-бабаларыбыз хәтере алдында бүгенге буын чын мәгънәсендә хыянәт кылган булачак.

# Ана теле бер булыр!

Татар кызы буларак, мине бүген иң борчыган нәрсә: яшьтәшләремнең үз ана телләрендә сирәк аралашуы. Нинди матур, җырдай моңлы телебезнең югалуына үзебез сәбәпче дип уйлыйм мин. Ютубтагы язмаларны карап, күңелемә шундый шикле уйлар килде, чөнки һәр милләт үз ана телендә сөйли, бары татар милләтеннән булганнар гына рус телендә чыгыш ясый. Ә бит нинди мул сүзлек хәзинәсенә ия безнең туган телебез.

Белгәнебезчә, татар теле - ЮНЕСКО тарафыннан бөтендөнья халыкара аралашу теле дип саналган ундүрт телнең берсе. Бу - туган телебез белән горурланырлык мөһим фактор түгелмени? Туган тел туган җир кебек кадерле һәм газиз, чөнки ул - кеше күңелендә иң нечкә, иң күркәм сыйфатлар тәрбияләүнең иң көчле чарасы. Ул - әби-бабай, әткәй-әнкәй теле, әйләнә-тирәне танып белергә, чиксез матурлыкларны аңларга, тоярга ярдәм итә торган тел. Тирән мәгънәгә ия булган «Һәр илнең ачкычы – тел» дигән мәкаль дә шуны раслый, минемчә.

Көндәлек тормышта без еш кына үзебез сөйләшә торган телне яки телләрне табигый бер нәрсә итеп кабул итәбез. Гаять зур әһәмияткә ия телебез тормыш-көнкүрешебезнең аерылгысыз бер өлеше булып тора. Фикерләү, тәртип һәм үзебезнең тормышыбызның рәвешенә, ысулына әйләнә. Шуңа күрә дә без аның төп функциясен - нәкъ менә аралашу һәм аңлашу функциясен онытып җибәрәбез. Бу тел - сабыйлык, изге гаилә тәҗрибәсе, башлангыч социаль мөнәсәбәтләр теле.

Без мәктәптә үткәрелгән тикшерену нәтиҗәсендә шундый фикергә килдек: югары сыйныф укучылары туган телебездә яхшырак аралаша. Урта сыйныфлар әле әби-бабай белән ана телебездә сөйләшәләр, ә менә яшьтәшләре белән үз телләрендә аралашу юк дәрәҗәсендә. Булса да ул: “кая киттең куда пошел, на мельницу тегермәнгә” кебек кулланыла. Түбән сыйныф укучыларының үз ана телләрендә аралашу дәрәҗәсе бер дә мактанырлык түгел. Алар аңласалар да, ана телендә җавап бирергә кыенсыналар. Әти-әниләр арасында сораштыру нәтиҗәләре шуны күрсәтте: әби-бабай булган гаиләдә әле балаларның ана телендә аралашу мөмкинлеге зуррак. Ни өчен шулай соң? Моны бүген ничек хәл итеп була икәнен төрле чыганаклардан кереп эзләргә керештек.

Эзләнә торгач, җаваплары да табылган кебек булды. Минем фикеремчә, телебезне югалтмау өчен татар теле һәм әдәбияты дәресләрен кыскартмаска кирәк. Татар балалар матбугатының сыйфатын күтәрергә, радио-телевидение аркылы аралашу, эш кәгазьләрен ике дәүләт телендә дә алып бару, төрле милләт кешеләре өчен татар телендә аралашу ихтыяҗы булдыру кирәк.

**Аделя Мөхәммәтҗанова,**
9Б сыйныфы



*20 апрель көнне ГабдуллаТукай иҗатына багышланган “Тамчы-шоу” уены узды. Безнең мәктәп укучылары әлеге чарада катнашып, 2нче урынга лаек булдылар.*


**Редактор** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.

***Ответственный секретарь*** Рузаль Шарипов

***Фотокорреспондент*** Диана Галимова

***Корректор*** Данил Степанов

***Редколлегия*** Алия Хабирова

Эльвина Хайрутдинова

***Адрес:*** ул. Мостовая, дом 15

***Сайт школы*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2

1972 Арск школа №2